| Республика Татарстан Старо-Имянское сельское поселение Сармановского муниципального района | Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районынын Иске Имән авыл жирлеге |
|---|---|

**КАРАР** **КАРАР**

**30.01.2026 ел** **№ 2**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл жирлеге муниципаль берәмлегендә жирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «җирләү һәм күмү эше турында»» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, "2026 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында" Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2026 елның 23 гыйнварындагы 30 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл жирлеге башкарма комитеты КАРАР итте:

1.Сарман муниципаль районының «Иске Имән авыл жирлеге» муниципаль берәмлегендә жирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен кушымталар нигезендә 2026 елның 1 февраленнән 9 678,63 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл жирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл жирлеге муниципаль берәмлегендә жирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында» 2025 елның 30 гыйнварындагы 1 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2026 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Интернет»мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә

рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Иске Имән авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе Р.Ә.Исламова

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге башкарма комитеты карарына кушымта
30.01.2026 ел, №2

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Иске Имән авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт тарафыннан иренә, якын туганнарына, башка туганнарына, законлы вәкиленә яисә мәрхүмне җирләү бурычын үз өстенә алган башка затка күрсәтелә торган җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе
2026 елның 1 февраленнән

| № п/п | Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум.) |
|---|---|---|
| 1. | Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | – |
| 2. | Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 4 170,37 |
| 3. | Мәетнең гәүдәсен (гәүдә калдыкларын) зиратка күчерү | 1 913,26 |
| 4. | Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3 595,00 |
| | Барлыгы: | 9 678,63 |

Татарстан Республикасы Сарман
муниципаль районы Иске Имән авыл
җирлеге башкарма комитеты карарына
кушымта
30.01.2026 ел, №2

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Иске Имән авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә үлгән кешенең тормыш иптәше, якын туганнары, бүтән туганнары йә законлы вәкиле булмаганда яисә алар тарафыннан җирләү мөмкинлеге булмаганда, шулай ук үлгән кешене өйдә, урамда яисә Эчке эшләр органнары тарафыннан билгеләнгәннән соң җирләү, җирләү бурычын үз өстенә алган башка затлар булмаганда җирләү мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт тарафыннан күрсәтелә торган җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе
2026 елның 1 февраленнән

| № п/п | Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе-(сум.) |
|---|---|---|
| 1. | Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | – |
| 2. | Кәфенләү | 1 500,00 |
| 3. | Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2 670,37 |
| 4. | Мәетнең гәүдәсен (гәүдә калдыкларын) зиратка күчерү | 1 913,26 |
| 5. | Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3 595,00 |
| | Барлыгы: | 9 678,63 |